| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЮРТОВСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ ЮРТАУ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

# КАРАР

№ 11 16.04.2018 ел

Янгын сүндерүнең беренчел чаралары исемлеген раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69 – ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Минзәлә муниципаль районы авыл җирлекләре торак пунктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын гамәлгә ашыру максатларында янгын сүндерүнең беренчел чаралары исемлеген раслау хакында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 25.04.2012 ел no 390 янгынга каршы режим турында карары нигезендә

**К А Р А Р Ч Ы Г А Р А М:**

1. Кушымталар нигезендә янгын сүндерүнең беренчел чаралары исемлеген расларга.
2. Җирлекнең торак пунктлары территориясендә йорт хуҗаларына алар милкендәге индивидуаль торак йортларны, беренчел янгын сүндерү чаралары белән тәэмин итүне расланган исемлек нигезендә тәкъдим итәргә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм районның рәсми сайтында бастырып чыгарырга.
4. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче: И.Ю.Кадыров

1 нче кушымта
Карар
16.04.2018ел № 11

# ИСЕМЛЕК
индивидуаль торак йортлар өчен янгын сүндерүнең беренчел чаралары

| Янгын сүндерүнең беренчел чаралары аталышы | саны (шт) |
|---|---|
| Су (200 литр) яки янгын сүндерүче порошок (ОП-5). | 1 |
| Штык көрәкләре | 1 |
| Совковой көрәк | 1 |
| Лом | 1 |
| Чиләк (10 литр) | 2 |
| Балта | 1 |
| Баскыч( торак йортның кәрнизенә кадәр килеп җитә) | 1 |

ИСКӘРМӘ:
Янгын сүндерү чараларын янгын очрагында файдалану өчен уңайлы урында компакт рәвештә урнаштырырга.